ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 10-55/кс

Эчә торган суга һәм су бүлүгә 2018 елга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчә торган суга һәм су бүлүгә шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаларга иректе файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-55/кс карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчә торган суга һәм су бүлүгә 2018 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| №<br>п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф<br>(бер ставкалы),<br>сум/куб м. | | Су бүлүгә тариф<br>(бер ставкалы),<br>сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Осиново» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | | | | |
| 1.1 | Воронино авылы һәм Ремплер саласы кулланучылары | 14,27 | 14,87 | | |
| 1.2 | Яңа Тура авылы кулланучылары | 14,63 | 15,22 | | |
| 2 | «Нижневязовской жилкомсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 28,21 | 29,33 | 14,97 | 15,57 |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | |
| 3 | «Су белән тәэмин итү һәм канализация үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | | | | |
| 3.1 | Комлы Ковал, Орлов, Столбище авыл җирлекләре кулланучылары | 33,07 | 34,37 | 40,60 | 40,60 |
| 3.2 | Габишево авыл җирлеге кулланучылары | 23,53 | 24,51 | 38,80 | 40,15 |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы | | | | |
| 4 | «Яңа Чишмә ТКХ КҖП» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 23,53 | 24,47 | 28,35 | 29,49 |
| | Нурлат муниципаль районы | | | | |
| 5 | «Промочистка» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | | | | |

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб м. | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр |
| 5.1 | Биккол, Биләркүл, Гәйтән, Егоркино, Ялаур, Заречный, Кычытканлы, Мамык, Би Күле, Урта Камышлы, Төрнәс, Чулпан, Иске Чаллы, Киекле, Әхмәт, Әмзә, Фома, Иске Әлмәт, Сәләнгеш, Яңа Иглай, Колбай-Мораса, Тимерлек авыл җирлекләре кулланучылары | 24,65 | 25,08 | | |
| | Спас муниципаль районы | | | | |
| 6 | «Спас су каналы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 38,14 | 39,68 | | |
| | Чирмешән муниципаль районы | | | | |
| 7 | «Чирмешән районы коммуналь челтәрләре» муниципаль унитар предприятиесе* | 26,99 | 27,86 | 43,65 | 45,31 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге